| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.03.2019 Балык Бистәсе штп. № 103пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте турында Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2011 елның 21 ноябрендәге “Бердәм “112” номеры буенча кичектергесез оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү турында” 958 номерлы карарына туры китереп, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Хөкүмәт комиссиясенең 2015 елның 28 августындагы 7 номерлы беркетмәсе, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге 2446-р номерлы ““Хәвефсез шәһәр” аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясе”, ”Гадәттән тыш хәлләрдә куркынычсызлык. Бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте. Төп нигезләмәләр” Р 22.7.01-2016 ГОСТ ы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Балык Бистәсе муниципаль районының бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте турында кушымта итеп бирелүче яңа редакциядәге Нигезләмәне расларга.

2..Балык Бистәсе муниципаль районының Бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте функцияләрен “Балык Бистәсе муниципаль районы гражданнарны яклау идарәсе” МКУ нә (үзидарәлек казна учреждениесенә) йөкләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 13 мартындагы
103 пи номерлы карарына
кушымта

Балык Бистәсе муниципаль районының
бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1.Гомуми нигезләмәләр
1.1. Төп төшенчәләр

1.1.1.Әлеге Нигезләмә Балык Бистәсе муниципаль районы бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтенең (алга таба – БКДХ) көндәлек эшчәнлек, күтәренке хәзерлек һәм гадәттән тыш вәзгыять режимында (ГВ) хәл итә торган бурычларының составын, структурасы һәм эшләү тәртибен билгели.

1.1.2. Нигезләмә Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә “Хәвефсез шәһәр” аппарат-программа комплексын төзү (кертү), үстерү һәм файдалануны, Россия Федерациясе субъектларында “112” номеры буенча кичектергесез оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын (112 системасы) булдыруны исәпкә алып эшләнде.

1.1.3. БКДХ үзидарәлек дәрәҗәсендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасы (алга таба – РГХС) белән Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлдә булган кизү тору һәм диспетчерлык (кизү-диспетчерлык) хезмәтләренең гамәлләрен килештерү өчен аталган һәм халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле идарә итү органнары каршында һәм / яки җирле үзидарәләрдәге гражданнар оборонасы органнары каршында төзелә торган көндәлек идарә итү органы булып тора.

1.1.4. БКДХ үз вәкаләтләре чикләрендә муниципаль районның табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр (алга таба – ГХ) (вакыйгалар) турында мәгълүмат җыйнау, эшкәртү һәм алмашу һәм ГХ (вакыйгалар) барлыкка килү куркынычы булганда яисә алар килеп туганда бергәләп эш итү мәсьәләләре буенча милек формасына бәйсез рәвештә барлык кичектергесез оператив хезмәтләре һәм оешмаларының (объектларының) кизү-диспетчерлык хезмәтләре (алга таба – КДХ) белән элемтәдә булып хезмәттәшлек итә.

1.1.5. Бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте (БКДХ) булдыруның максаты булып районның җирле үзидарә органнарының һәм хезмәтләренең гадәттән тыш хәлнең (вакыйганың) килеп чыгу куркынычына яисә барлыкка килүенә илтифат итүгә әзерлеген, РГХС чараларының һәм җәлеп ителә торган көчләрнең, шул исәптән кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) аларның гадәттән тыш хәлләрне (вакыйгаларны)

кисәтү һәм бетерү буенча бергәлектә гамәл кылу барышында хезмәттәшлек нәтиҗәлелеген күтәрү, шулай ук гражданнар оборонасы (алга таба – ГО) чараларын һәм хәзерлеккә китерү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, муниципаль берәмлекләр чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән кешеләрнең су объектларында иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрен үтәүләрен тәэмин итү тора.

## 1.2. Балык Бистәсе муниципаль районының БКДХ нең төп бурычлары

1.2.1. БКДХ түбәндәге төп бурычларны үти:

- ГХ (вакыйгалар) турында чакырулар (хәбәрләр) кабул итү;
- хәбәр итү сигналларын кабул итү, хәбәр итү сигналларын алу турындагы мәгълүматны . Балык Бистәсе муниципаль районының вазыйфаи затларына ирештерү һәм хәбәр итүне район буенча оештыру;
-гражданнар оборонасы (ГО), РГХС территориаль ярдәмче системасының үзидарәлек звеносы, идарә итү органнары, муниципаль район территориясендәге гадәттән тыш хәлләрдән (вакыйгалардан) кисәтү һәм аларны бетерү өчен аталган һәм бүленә (җәлеп ителә) торган көч һәм чаралар җитәкчелегенә, халыкка һәм гадәттән тыш хәлләр (вакыйгалар), районадагы гадәттән тыш хәлләр (вакыйгалар) буенча күрелгән чаралар турында җирле (Балык Бистәсе муниципаль районында гамәлдәге) хәбәр итү системасы аша, ГО сигналлары буенча кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләренә хәбәр итү һәм мәгълүмат җиткерү
- килеп ирешкән мәгълүматның дөреслеген анализлау һәм бәяләү, аны кабул ителгән хәбәргә илтифат итү үз вәкаләтенә кергән КДХ нә җиткерү;
- ГХ ләрне (вакыйгаларны) кисәтү һәм бетерү буенча идарә итү карарларын хәзерләү һәм кабул итү, шулай ук аларның үтәлешенә контроль ясау өчен кирәкле мәгълүматларны җыйнау һәм эшкәртү;
- КДХ ләреннән, әйләнә-тирә мохитне күзәтү һәм контрольдә тоту хезмәтләреннән, мониторинг системаларыннан мәгълүматлар җыю һәм алынган ГХ (вакыйга) куркынычы яисә аның барлыкка килү факты, килеп туган хәл һәм ГХ не (вакыйганы) бетерү буенча көч һәм чараларның кылган гамәлләре турындагы мәгълүматларны Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә эшләп килүче КДХ ләре арасында тарату;
- ГХ ләр (вакыйгалар) турындагы мәгълүматларны эшкәртү һәм анализлау, аның масштабын аныклау һәм ГХ гә илтифат итү өчен җәлеп ителүче КДХ ләренең составын ачыклау, РГХС ның эшләү режимнарының берсенә күчерү турында аларга хәбәр итү;
-вәзгыять хакындагы мәгълүматларны, гадәттән тыш хәлне бетерү буенча күрелгән чараларны гомумиләштерү, бәяләү һәм контрольгә алу һәм вакыйгага илтифат итү, Балык Бистәсе муниципаль районы хезмәтләре белән гадәттән

тыш хәлне (вакыйганы) бетерү буенча идарә итү карарларының алдан эшләнгән һәм килештерелгән вариантларына төзәтмәләр кертү, кичектергесез чаралар һәм зарури карарлар кабул итү (югары органнар тарафыннан билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә);
-вәзгыять хакында ГХ ләрне (вакыйгаларны) бетерүгә җәлеп ителгән КДХ енә, даими әзерлекле кул астындагы көчләргә хәбәр итү;
- ГХ ләрнең (вакыйгаларның) куркынычы булуы яки аларның барлыкка килүе, килеп туган вәзгыять турында, ГХ ләрне (вакыйгаларны) элек әзерләнгән һәм яраштырылган планнар нигезендә бетерү буенча хәл итүнең мөмкин булган вариантлары һәм гамәл кылулар турында донесениеләр тәкъдим итү;
-җитәкчелек тарафыннан куелган бурычларны КДХ ләренә һәм даими әзерлектәге кул астындагы көчләргә җиткерү һәм үзара тәэсир итешү, хезмәттәшлекне оештыру;
- булган ГХ ләр (вакыйгалар), аларны бетерү буенча эшләр турында оператив мәгълүмат бирү һәм буйсынучанлык тәртибендә тиешле докладлар тапшыру;
-кабул ителгән карарларны һәм эшләнгән планнарны башкаручыларга җиткерү, килеп туган вәзгыять, үтәлә торган карарлар һәм үткәрелүче чаралар барышы хакында кызыксынучы югарыгы һәм хезмәттәшлек итүче оешмаларга хәбәр итү;
-“112” бердәм номеры буенча килүче чакыруларга (булган вакыйга, хәл турындагы хәбәрләргә) илтифат итүче җәлеп ителгән КДХ ләренең гамәлләрен анықлау һәм төзәтмәләр кертү;
- Балык Бистәсе муниципаль районы территориясеннән “112” бердәм номеры буенча килүче чакыруларга (булган вакыйга, хәл турындагы хәбәрләргә) илтифат итү нәтиҗәләренә контрольлек итү;
1.2.2. Үзидарәлек дәрәҗәсендәге яки тагы да зуррак колачлы ГХ вакытында җирле үзидарә органының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясенә, шулай ук җирле үзидарә каршындагы халыкны һәм территорияләрне ГХ ләрдән саклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле һәм / яки гражданнар оборонасы органына кичекмәстән хәбәр ителеп алар хәзерлеккә китерелә. Болар ГХ не кисәтү һәм бетерү буенча алга таба кылыначак гамәлләр белән идарә итүне үз өсләренә алалар. Әлеге вәзгыятьләрдә БКДХ мәгълүмат туплау, эшкәртү һәм тапшыруны (тәкъдим итүне) тәэмин итә.

1.2.3. БКДХ Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә эш итүче барлык КДХ ләре өчен югарыгы орган, ГХ турында мәгълүмат туплау, эшкәртү, анализлау һәм алмашу мәсъәләләре буенча, шулай ук ГХ гә илтифат итүче һәм гадәттән тыш хәлләрдә КДХ ләренең бергәләп эш итү мәсьәләләре буенча яраштыручы орган булып тора.

1.2.4. БКДХ нең эш итүе муниципаль берәмлектә булган хәлләр, вакыйгалар хакында аның барлыкка килүенә кадәр гамәлдә булган халыктан (01,02, 03, 04 һ.б. телефоннар буенча ) хәбәрләр кабул итү тәртибен юкка чыгармый.

1.2.5. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ тәүлек буена эшли һәм шул ук вакытта тиеш:

-кичекмәстән КДХ ләренә хәбәр итү һәм мәгълүмат җиткерү эшенә, аларның тырышлыкларын ГХ не кисәтү һәм/яки бетерү буенча яраштыруга , шулай ук кирәкле мәгълүматларны алганнан соң вакыйгаларга илтифат итүгә керешергә;

-әгәр килеп туган вәзгыять идарә итүнең югарыгы органнары белән кичектергесез гамәлләрне килештерү өчен мөмкинлек бирмәсә, үзенең вәкаләтләре кысаларында кешеләрне саклау һәм коткару буенча мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итәргә.

1.2.6. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ ГХ ләрдән халыкны һәм территорияләрне саклау өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә махсус вәкаләтле органнар каршында оештырыла.

1.2.7. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ белән гомуми җитәкчелек итүне җирле үзидарә органы җитәкчесе гамәлгә ашыра, турыдан-туры җитәкчелекне – "Гражданнарны саклау идарәсе"МКУ җитәкчесе.

1.2.8. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы буенча Россия ГХМ (МЧС) баш идарәсенең (алга таба – ГХМ ның БИ) авыр хәлләрдә идарә итү үзәге белән үзара бәйләнештә гамәлгә ашыра.

## 1.3. Составы һәм структурасы

1.3.1. БКДХ штаттагы ( ул төзелә торган идарә органындагы өстәмә сан хисабына) яки штатта тормау нигезендә ( гамәлдәге идарә органнарының вазыйфаи затларын кизү торуга тарту исәбенә) оештырыла.

1.3.2. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ үз эченә алырга тиеш:

-кизү-диспетчерлык персоналын;

- идарә итү пунктын;

-идарәнең техник, элемтә һәм хәбәр итү чараларын,

- БКДХ нең автоматлаштыру чаралары комплексын.

1.3.3. БКДХ нең кизү-диспетчерлык персоналы составында тәүлек әйләнәсе кизү тору исәбеннән оператив кизү тору сменалары каралган булырга тиеш. Һәр сменага мәҗбүри тәртиптә оператив кизү һәм аның ярдәмчесе кертелергә тиешле.

1.3.4. БКДХ нең элемтә үзәге (алга таба – БКДХ нең ЭҮ) түбәндәге бурычларны хәл итә:

-идарәнең документларын кабул итү һәм тапшыру, билгеләнгән контроль срокларда һәм таләп ителә торган сыйфат белән югарыгы, хезмәттәшлек итүче һәм буйсынудагы органнар белән барлык төр мәгълүмат алмашу;

-хәбәр итү сигналларын җиткерү;

- идарәнең югарыгы, хезмәттәшлек итүче һәм буйсынудагы органнары һәм көчләр белән элемтә оештыру.

1.3.5. Шул ук вакытта БКДХ тәэмин итәргә тиеш:

-элемтә чараларының тотрыклы эшләвен;

- бирелгән эш режимнарында гамәлдәге элемтәләрне туктатмау һәм планлаштырылган һәм яңа оештырыла торган элемтәләрне үзвакытында урнаштыруны тәэмин итүне;

-күчмә элемтә чараларының привязкасы өчен элемтә чаралары һәм корылмаларының техник әзерлеген;

-идарә итү пунктында эчке элемтәне, шул исәптән каты тавышлы элемтәне;

- элемтә һәм хәбәр бирүнең куркынычсызлыгын;

- БКДХ белән Татарстан Республикасы буенча Россия ГХМ БИ нең КХИҮ (кризислы хәлләрдә идарә үзәге) арасындагы, шулай ук Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендәге КДХ ләре белән туры телефон элемтәсе каналларын;

-гомуми файдаланудагы шәһәр телефон челтәренең күпканаллы телефон номеры буенча мәгълүмат кабул итү;

-керүче әбунәче номерын автоматик рәвештә билгеләү;

-бара торган сөйләшүләрне документлаштыру (язып алу);

-кабул ителгән хәбәрне районның тиешле КДХнә тоташтыруны (коммутацияне) (сайлап алып һәм циркуляр рәвештә);

-стационар һәм күчмә әбунәчеләр белән радиоэлемтә.

1.3.6. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең элемтә чаралары тәэмин итәргә тиеш:

-радиоэлемтәне;

- телефон элемтәсен;;

- мәгълүматлар тапшыруны;

- командаларны, хәбәр итү сигналларын һәм мәгълүматларны кабул итү һәм тапшыруны;

-чакыруларны (хәбәрләрне) “112” бердәм номеры аша кабул итүне;

-тапшырыла торган хәбәрне кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) тиешле КДХ ләренә тоташтыруны (коммутацияне);

-сөйләүле хәбәрләр, документаль һәм видеомәгълүмат белән, шулай ук югарыгы һәм хезмәттәшлек итүче хезмәтләр белән мәгълүматлар алмашуны.

Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ элемтәнең запас каналларын булдырырга тиеш. Элемтә чаралары гомуми файдаланудагы элемтә челтәре белән бәйләнешне тәэмин итәргә тиеш.

1.3.7. БКДХ нең автоматлаштырылган мәгълүмати системасы (алга таба – БКДХ нең АМС) БКДХ нең бурыч һәм функцияләрен үтәүнең автоматлаштырылуын тәэмин итә. БКДХ нең АМС Россия гадәттән тыш хәлләр системасы (РГХС) республика һәм төбәк автоматлаштырылган мәгълүмати-идарә системасы һәм кичектергесез оператив хезмәтләр һәм оешмаларның (объектларның) хезмәттәшлек итүче КДХ ләренең булган автоматлаштырылган системалары белән, шулай ук 112 системасының телекоммуникацион ярдәмче системасы белән бәйләнә.

1.3.8. БКДХ нең автоматлаштыру чаралары комплексы (АЧК – КСА- комплекс средств автоматизации)) БКДХ персоналы тарафыннан түбәндәге функцияләрне автомат рәвештә үтәүне тәэмин итү өчен аталган:

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгына, җирле хакимият һәм кызыксынучы бүтән җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында тулы, ышанычлы һәм актуаль мәгълүматны үзвакытында тапшыруны;
- КДХ ләре тарафыннан ГХ не (вакыйганы) кисәтү һәм бетерү буенча идарә итү карарларын кабул итү өчен нигезле, килештерелгән тәкъдимнәрне оператив төстә әзерләү һәм башкаручыларга җиткерүне;
-үзидарәлек районы, даими әзерлек көчләре һәм чаралары турындагы мәгълүматларны ГХ ләрдә, потенциаль куркыныч объектларда, кискен әһәмиятле объектларда, транспорт инфраструктурасы һәм яшәү тирәлеге объектларында, ГХ не кисәтү һәм бетерү буенча мөмкин булган һәм планлаштырыла торган чараларда файдалануны;
-ГХ куркынычы һәм аның барлыкка килү факты, килеп туган вәзгыять, көчләрнең һәм чараларның гамәлләре турында мәгълүматлар туплау һәм тапшыруны;
-төрле автоматлаштырылган системалардан һәм читтәге җайланмалардан килүче мәгълүматлар нигезендә килеп туган вәзгыятьне мониторинглау, анализлау, бәяләү һәм контрольне;
-ГХләрне кисәтү һәм бетерү буенча карарлар кабул итү өчен мәгълүматлар әзерләүне, аларны Балык Бистәсе муниципаль районы территориясенең электрон (цифрлы) картасында чагылдыруны;
-мәгълүматларны җитәкчелеккә һәм үзара бәйләнештәге хезмәтләргә бирүне.

1.3.9. БКДХ нең автоматлаштыру чаралары комплексы (АЧК) бәйләнергә тиеш:

- үзара бәйләнештәге (хезмәттәшлек итүче) КДХләренең автоматлаштырылган системалары белән;
-хәбәр итү һәм мәгълүмат җиткерү системалары белән;
-112 системасы белән;
-мониторинглау системалары белән, видеокүзәтү системаларын, юл йөрү кагыйдәләрен, янгын һәм тревога сигнализацияләрен бозуларның, фото-,видеофиксация, эзләү-навигация (ГЛОНАСС/GPS) системаларын, ТКХ (торак-коммуналь хуҗалык) объектларын мониторинглау, эко мониторинг системаларын да кертеп;
-лаборатория контроле системалары белән;
-мәгълүмати-аналитика системалары белән;
- РГХСның төбәк дәрәҗәсендәге автоматлаштырылган мәгълүмати-идарә итүче системасы (АМИС) (алга таба – РГХСның АМИС) белән;
- гамәлдәге һәм перспективалы бүтән системалар белән.

БКДХ нең автоматлаштыру чаралары комплексының (АЧК) методик, мәгълүмати, лингвистик һәм хезмәттәшлек итүче КДХ ләрнең автоматлаштырылган системалары белән, шулай ук идарә итүнең югарыгы

дәрәҗәсенең РГХС ның АМИС белән программа-техник яктан берләшүен (кушылуын) тәэмин итү өчен үткәрелә торган исәпләүләрнең бердәм алгоритмик (математик) тәэмин ителеш, бердәм классификаторлар һәм мәгълүмат сүзлекләре, шулай ук РГХС ның АМИС нда кабул ителгән мәгълүматларны эшкәртү һәм тапшыруның бер типтагы техник һәм программа чаралары каралырга тиеш.

## II. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең эшен оештыру

### 2.1. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең эшләү режимы

2.1.1. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ көндәлек эшчәнлек, күтәренке әзерлек һәм тыныч вакыт өчен гадәттән тыш хәл режимында эшли. Гражданнар оборонасын әзерлеккә китергәндә һәм сугыш вакытында әзерлекнең тиешле дәрәҗәләрендә.

2.1.2. БКДХ өчен эшләү режимын Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе – гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча ТР Балык Бистәсе муниципаль районы комиссиясе рәисе билгели (алга таба – Председатель КЧС и ОПБ (ГХ һәм ЯКТК рәисе).

2.1.3. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ көндәлек эшчәнлек режимында ГХ барлыкка килү куркынычына яисә барлыкка килүгә кичектергесез илтифат итүгә әзерлектә тәүлек әйләнәсе кизү торуны гамәлгә ашыра. Бу режимда Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ тәэмин итә:

- халыктан һәм кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ лареннән теләсә нинди ГХ лар (вакыйгалар) турында хәбәрләр кабул итүне, КДХ ләренеке булу һәм җаваплылык дәрәҗәсе буенча аларны теркәүне, ГХ (вакыйга) барлыкка килү куркынычына яисә барлыкка килү турында мәгълүматны буйсынучанлык һәм карамакта булу тәртибендә Татарстан Республикасы буенча Россия ГХМ БИ нең КХИҮ нә тапшыруны;

-хәбәр итү сигналларын кабул итү һәм аларны расланган инструкцияләр нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затларына җиткерүне;

-агымдагы тәүлекләрдәге ГХ лар (вакыйгалар) турында мәгълүматларны анализлау һәм гомумиләштерүне һәм тиешле докладларны җитәкчелеккә тапшыруны;

- автоматлаштыру чаралары комплексын (АЧК) даими оператив хәзерлектә тотуны;

- җаваплылык зонасындагы кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләренең әзерлегенә контрольне, вәзгыять һәм аның үзгәрешләре турында аларның кизүдәге сменаларына оператив хәбәр итүне;

-мәгълүматлар базасына, шулай ук ГХ ларга (вакыйгаларга) илтифат итү буенча оператив документларның структурасына һәм эчтәлегенә кирәкле үзгәрешләрне кертүне.

2.1.4. Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан КДХ ләре көндәлек эшчәнлек режимында үзләренең инструкцияләре нигезендә эш итәләр һәм . Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХнә узган тәүлекләрдәге ГХ ләр (вакыйгалар) һәм аларның барлыкка килү куркынычлары хакында гомумиләштерелгән статистик мәгълүмат тапшыралар

2.1.5.Кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре ГХ (вакыйгалар) барлыкка килү куркынычы яисә барлыкка килү хәбәренә тәңгәлләштерә торган хәбәрләр беренче нәүбәт тәртибендә Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нә тапшырылалар, ә Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ мәгълүматны Татарстан Республикасы буенча Россия ГХМ БИ нең КХИҮ нә тапшыра.

2.1.6. Күтәренке хәзерлек режимына Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ һәм җәлеп ителгән кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре ГХ (вакыйга) барлыкка килү куркынычы булганда җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән куркынычны бетерү өчен Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ белән хезмәттәшлек итүче КДХ ләре һәм РГХС көчләренең бергәләп эш итүе таләп ителгән очракларда күчерелә.

Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ күтәренке хәзерлек режимында тәэмин итә:

- тиңдәшле ГХ (вакыйга) барлыкка килү очрагында зарури гамәлләргә алдан әзерлекне;

- ГХ ләр һәм ЯКТ комиссиясенең вазыйфаи затларына һәм Балык Бистәсе муниципаль районы җитәкчелегенә, Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ, кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре белән хезмәттәшлек итүче һәм буйсынудагы РГХС көчләренең җитәкчелегенә хәбәр итүне;

- Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендәге, потенциаль хәвефле объектларда (ПХО – ПОО) вәзгыятьне, шулай ук әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтү һәм контрольдә тотуның мәгълүматларын алу һәм гомумиләштерүне;

- вәзгыять үсешен фаразлауны һәм җәлеп ителә торган көч һәм чараларның гамәлләре буенча тәкъдимнәр хәзерләүне;

- кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре, РГХС көчләре тарафыннан ГХне (вакыйганы) булдырмый калу һәм аның нәтиҗәләрен йомшарту буенча кичектергесез чаралар күрелгәндә гамәлләрен килештерүне.

2.1.7. ГХне (вакыйганы) булдырмый калуны оештыру өчен ГХ һәм ЯКТК яки Татарстан Республикасының оператив штабының эше оештырылу очрагында Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ күрсәтелгән ГХ буенча гамәл кылу өлешендә аларның күрсәтмәләрен үти.

2.1.8.Гадәттән тыш хәл режимына Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ, җәлеп ителүче кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре һәм РГХС көчләре гадәттән тыш

хәл барлыкка килгәндә Башкарма комитет җитәкчесе карары белән күчереләләр. Әлеге режимда Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ түбәндәге бурычларны үти:

- кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре һәм җәлеп ителүче РГХС көч һәм чараларының табигый һәм техноген характерындагы ГХ дән халыкны һәм территорияне саклау буенча эшләр үткәргәндә гамәлләрен яраштыру;

- оператив төркемнәрне күчерү һәм Балык Бистәсе муниципаль районы территориясе буенча аларның хәрәкәт итүен күзәтеп баруны контрольдә тоту;

- тиңдәшле ГХ не бетерүне оештырганда һәм авария-коткару эшләре барышында, икътисад объектларының тотрыклы эшләвен тәэмин итү һәм зыян күргән халыкның беренче чиратта тормыш эшчәнлеген тәэмин итү буенча чаралар оештырганда идарә итү органнары арасында хәбәр итү һәм оператив мәгълүматны тапшыру;

- ГХ гә тиңдәшле зонаны билгеләү һәм аның чикләренең күчешенә контрольлек итү, ГХ зонасындагы хәвефләр хакында үзвакытында хәбәр итү һәм халыкка мәгълүмат ирештерү;

- ГХ зонасында әйләнә-тирә мохитнең хәлен, авария объектларында һәм алар янәшәсендәге территориядәге вәзгыятьне өзлексез контрольдә тотуны гамәлгә ашыру.

2.1.9.Күтәренке хәзерлек һәм гадәттән тыш хәл режимнарында кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре, РГХС көчләре арасында мәгълүмати бәйләнеш турыдан-туры Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ аша гамәлгә ашырыла.

Килеп туган вәзгыять, күрелгән чаралар, катнашкан һәм таләп ителгән өстәмә көчләр һәм чаралар хакында килгән мәгълүмат Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ тарафыннан хезмәттәшлек итүче кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләренә, Балык Бистәсе муниципаль районы РГХС ның идарә органнарына, Татарстан Республикасы буенча Россия ГХМ БИ нең КХИҮ нә җиткерелә.

2.1.10. ГХне (вакыйганы) булдырмый калуны оештыру өчен ГХ һәм ЯКТК яки Татарстан Республикасының оператив штабының эше оештырылу очрагында Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ күрсәтелгән ГХ буенча гамәл кылу өлешендә аларның күрсәтмәләрен үти.

2.1.11. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең гражданнар оборонасын әзерлеккә китерүдә һәм сугыш вакытында эшләве гражданнар оборонасы һәм Россия Федерациясе субъекты халкын саклау планы һәм кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ нең кизү тору персоналына аерым чор шартларында эш итү буенча инструкцияләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.1.12. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ аерым чор шартларында эш иткәндә гражданнар оборонасы һәм Россия Федерациясе субъекты халкын саклау планы нигезендә идарә итүнең сакланган пунктларында оператив кизү тору сменаларын урнаштыру күздә тотыла.

## 2.2. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең эш тәртибе

2.2.1. ГХ ләр(вакыйгалар) турында халыктан чакырулар (хәбәрләр) Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нә элемтәнең барлык булган төрләре һәм каналлары буенча, ГЛОНАСС 112 программ тәэмин ителеш аша хәбәрләрне дә кертеп, сигнал һәи мониторинг системаларыннан, үзидарәлек районының кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләреннән, югарыгы һәм РГХС ның хезмәттәшлек итүче идарә органнарыннан туры каналлар һәм элемтә линияләре буенча керергә мөмкин.

2.2.2.Килеп чыккан вәзгыятьне ГХ ләр (вакыйгалар) буларак классификацияләгәндә Бистәсе муниципаль районы БКДХ мәгълүматны компетенцияләрендә килеп туган ГХ гә (вакыйгага) илтифат итү булган кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләренә һәм РГХС көчләренә җиткерә, зарурлык булганда җәлеп ителгән кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре гамәлләрен тәгаенли.

2.2.3. Килеп чыккан вәзгыятьне локаль дәрәҗәдән югары ГХ (вакыйга) буларак классификацияләгәндә (РФ Хөкүмәтенең 2007 елның 21 маендагы “Табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләрне классификацияләү турында” 304 номерлы Карары), Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ оператив кизүе кичекмәстән Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә – гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча ТР Балык Бистәсе муниципаль районы комиссиясе рәисенә, Татарстан Республикасы буенча Россия ГХМ БИ нең КХИҮ нә җиткерә, вәзгыятьне бәяли, җәлеп ителә торган көчләр составын һәм чараларны аныклый, аларга хәбәр итә. Бер үк вакытта ГХ факты турында алга таба Татарстан Республикасы буенча Россия ГХМ БИ нең КХИҮ нә тапшыру өчен формаль (рәсми) документлар (ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 4 апрелендәге 34пг карары белән расланган) хәзерләнә.

2.2.4. ГХ беленгәндә халыкка саклану ысуллары хакында мәгълүмат җиткерелә. Вәзгыять һәм кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре арасында җәлеп ителгән көчләр һәм чараларның гамәлләре турында мәгълүмат белән кирәкле алмашу, алынган мәгълүматларны чагыштыру һәм гомумиләштерү оештырыла, РГХС ның югарыгы идарә органнарына донесениеләр әзерләнә, барлык дәрәҗәдәге хакимиятләр эшчәнлегенә мәгълүмати булышлык күрсәтү һәм аларның ГХ не бетерүгә тартылган хезмәтләр белән бәйләнеше (хезмәттәшлеге) тәэмин ителә.

2.2.5. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ эшләвенә ай саен анализ ясала.

## 2.3. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре белән хезмәттәшлек тәртибе

. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре белән хезмәттәшлек тәртибе ведомствоара норматив хокукый актлар һәм Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты Советының хезмәттәшлек итү һәм һәлакәтләр, табигый бәла-казалар һәм ГХ ләр (вакыйгалар) вакытында кичектергесез оператив хезмәтләр арасында мәгълүмат алмашу тәртибен билгеләүче норматив хокукый актлары белән тәгаенләнә.

## II. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ составына карата таләпләр

### 3.1. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ н туплау һәм кадрларын әзерләү

3.1.1. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ н хезмәткәрләр составы белән комплектлау (үзидарәлек казна учреждениесе җитәкчесе буларак) "Балык Бистәсе муниципаль районы гражданнарны саклау идарәсе"МКУ се җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла. "Балык Бистәсе муниципаль районы гражданнарны саклау идарәсе"МКУ се җитәкчесе билгеләнгән тәртиптә Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм аннан азат ителә.

3.1.2. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ енең хезмәткәрләр (шәхси) составы хезмәтнең эшчәнлеген тәртипкә салучы җитәкче документларның таләпләрен белергә тиеш һәм аларны көндәлек эштә кулланырга бурычлы.

БКДХ документациясенең минималь составы:

-ГО, халыкны һәм территорияләрне габигый һәм техноген характердагы ГХ лардән саклау, янгын куркынычсызлыгы, шулай ук ГХ ләр (вакыйгалар) турында мәгълүмат җыйнау һәм алмашу мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар;

- БКДХ белән кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре һәм үзидарәлек районының тереклеген тәэмин итү хезмәтләренең мәгълүмати хезмәттәшлеге турында килешүләр;

-алынган һәм тапшырылган мәгълүматны, алынган һәм тапшырылган күрсәтмәләрне һәм сигналларны исәпкә алу журналы;

-оператив кизү тору журналы;

- ГХ нең (вакыйганың) барлыкка килү куркынычы булу яисә килеп чыгуы турындагы хәбәрне алганда оператив-кизү тору персоналы гамәлләре буенча инструкцияләр;

-көндәлек эшчәнлектә, күтәренке хәзерлек һәм гадәттән тыш хәл режимнарында кизү тору турында инструкцияләр;

- Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре белән үзидарәлек районы территориясендә төрле характердагы ГХ ләрне (вакыйгаларны), янгыннарны бетерү вакытында үзара хезмәттәшлек планы;

- кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) хезмәттәшлек итүче КДХ ләре линияләре буенча мәгълүмат алганда оператив кизү тору персоналының гамәлләре буенча инструкцияләр;

-химик яктан куркынычлы барлык матдәләргә һәм нурланышлы йөкләргә авария медицина карточкалары, ГХ ләрнең (вакыйгаларның) фаразланучы нәтиҗәләре белән нурланышлы, химик, биологик яктан куркыныч объектларның исемлеге;

-янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм хезмәтне саклау буенча инструкцияләр;

-ГО, РГХС ның территориаль ярдәмче системасының үзидарәлек звеносы, Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендәге идарә органнары, көчләр һәм чаралар җитәкчелегенә хәбәр итүнең схемасы һәм исемлекләре (саналып киткәннәрнең барысы да ГХне (вакыйганы) кисәтү һәм бетерү өчен аталганнар һәм бүленә (җәлеп ителә) торган Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендәге көчләр һәм ГО чаралары, ГХ (вакыйга) очрагында кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХләре) ;

- Балык Бистәсе муниципаль районы һәм ПХО ларның, шәһәр тибындагы поселокның һәм Балык Бистәсе муниципаль районының авыл торак пунктларының иминлек паспортлары, халыкны социаль яклау, сәламәтлек саклау объектларының комплекслы куркынычсыз торышы паспортлары, үзидарәлек районының эшче карталары (шул исәптән электрон рәвештә дә);

-чираттагы оператив кизү тору сменасына кизү торуга керешер алдыннан инструктаж үткәрү планы;

- оператив кизү тору сменаларының кизү тору графигы;

-идарә итү һәм чакыру схемалары;

-хәбәр итүнең җирле системасы схемасы;

-телефон белешмәлекләре;

- оператив-кизү тору персоналына һөнәри әзерлек үткәрүне оештыру буенча документлар;

- текстның алдан әзерләнгән даими өлешле эшкәртелә торган формаль (рәсми) бланклары;

- ГХРХ нең территориаль ярдәмче системасының үзидарәлек звеносының көч һәм чараларының тәүлеклек хисабы;

- үзидарәлек районының ГХ не (вакыйганы) бетерүгә җәлеп ителүче көч һәм чараларының хисабы;

- ГХ ләр (вакыйгалар) килеп чыгу куркынычы булганда һәм барлыкка килгәндә башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары белән мәгълүмат алмашу буенча инструкция;

- БКДХ нең оператив кизүенең көндәлек эш планы.

Оператив документлар составы БКДХ нең эшләү шартларыннан бәйле рәвештә тулыланырга мөмкин.

3.1.3. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең оператив-кизү персоналын өйрәтүнең төп формасы булып оператив кизү торучы сменаларның

тренировкалары, уку-укыту чараларында (өйрәнүләрдә) катнашуы һәм һөнәри хәзерлек буенча занятиеләр тора.

3.1.4. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең оператив-кизү персоналы белән үткәрелә торган уку-укыту чаралары (тренировкалар һәм уйрәнүләр) алдан ук эшләнгән һәм Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган план нигезендә Татарстан Республикасы буенча Россия ГтХМ БИ нең КХИҮ үткәргән өйрәнүләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3.1.5. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең оператив-кизү тору персоналын һөнәри әзерләү Россия ГХМ ның махсус эшләнгән программасы буенча уздырыла.

3.1.6. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХнең оператив-кизү тору персоналын әзерләү гамәлгә ашырыла:

-Татарстан Республикасының ГО һәм ГХ буенча Укыту-методик үзәгендә, ГО курсларында, янгынга каршы дәүләт хезмәтенең федераль янгынга каршы хезмәтенең укыту үзәкләрендә һәм укыту пунктларында, күрсәтелгән эшчәнлек төре белгечләрен әзерләү буенча тиешле лицензияләре булган бүтән белем бирү учреждениеләрендә;

-Россия ГХМ тарафыннан махсус эшләнгән тематика нигезендә һөнәри әзерлек буенча занятиеләр үткәрү барышында ай саен 6-8 әр сәгать. Тематика хәл ителә торган мәсьәләләрдән һәм ГХ (вакыйга) характерыннан, шулай ук белгечнең шәхси әзерлегеннән чыгып аныклана;

- Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХнең оператив-кизү персоналына оператив кизү торуга керешкәндә көнлек инструктаж үткәрү барышында;

- Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХнең оператив кизү тору сменасы белән Татарстан Республикасы буенча Россия ГХМ БИ нең КХИҮ тарафыннан үткәрелүче тренировкалар барышында;

- кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләренең оператив кизү тору сменалары белән тренировкалар үткәрү, РГХС органнары һәм көчләре төрле өйрәнүләр һәм тренировкалар үткәрү барышында, аларга үзидарәлек районының кичектергесез оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның (объектларның) КДХ ләре җәлеп ителә;

Шуның белән бергә һәрбер оператив кизү тору сменасы өйрәнүләрдә һәм тренировкаларда елына кимендә 2 тапкыр катнашырга тиеш.

3.1.7. БКДХнең оператив кизү тору персоналын әзерләү барышында ГХ ләрнең (вакыйгаларның) килеп чыгу куркынычы булу яисә аның барлыкка килүе турында мәгълүматны кабул итүне оештыруга, РГХС ның идарә органнарына һәм көчләренә, халыкка үзвакытында җиткерүгә, шулай ук ГО на хәбәр итү сигналларын ирештерүгә аерым игътибар юнәлтелә.

3.1.8. БКДХнең оператив кизү персоналының практик стажировкасы Татарстан Республикасы буенча Россия ГХМ БИ нең КХИҮ базасында стажировка графиклары һәм планнарына туры китереп оештырыла.

Ярты елга кимендә бер мәртәбә зачетлар кабул ителә, аларның нәтиҗәләре нигезендә БКДХнең оператив кизү тору персоналын оператив кизү торуга рөхсәт итү турында карар кабул ителә.

Квартал саен персоналны әзерләү буенча эшнең торышы анализлана һәм Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тапшырыла.

### 3.2. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ оператив кизү тору персоналына таләпләр

3.2.1. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ оператив кизү персоналы һәм җитәкчелеге белергә тиеш:

- Балык Бистәсе муниципаль районының административ структурасын һәм Россия Федерациясе. субъектының 112 системасы структурасын. Балык Бистәсе муниципаль районы куркынычсызлык системасы җитәкче составының фамилияләрен һәм вазыйфаларын һәм Балык Бистәсе муниципаль районында күрсәтелгән система структурасына кергән кизү тору хезмәтләренең авария-коткару берләшмәләре адресларын;
- Балык Бистәсе муниципаль районының административ чикләрен, янгын сүндерү-коткару подразделениеләренең чыгу урыннарын, Балык Бистәсе муниципаль районындагы урыннарның исем-атамаларын һәм транспорт магистральләрен;
- Балык Бистәсе муниципаль берәмлектәге кизү-диспетчерлык хезмәтләре системасын оештыруны;
- Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең территориаль җаваплылык зонасын һәм Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә эш итүче кичектергесез илтифат итү хезмәтләренең территориаль җаваплылык зоналарын;
-ГХләрне (вакыйгаларны) кисәтү һәм бетерү өчен җәлеп ителгән техниканың урнашуын, билгеләнешен, коткару һәм янгын сүндерү махсус чаралары складларының урнашуын;
- Балык Бистәсе муниципаль районының чыгу урыннарында урнашкан потенциаль хәтәр объектларны, социаль яктан әһәмиятле объектларны, аларның адресларын, тулы аталышын, янгын һәм авария-коткару техникасының рангка тиңдәшле билгеләнгән җыелмасын;
- БКДХ нең автоматлаштырылган системасының билгеләнешен һәм тактик-техник характеристикасын, аңа йөкләнгән бурычларны үтәү тәртибен, элемтә чараларыннан һәм БКДХ нең идарә итү пунктында урнаштырылган башка җиһаздан файдалану тәртибен;
-Татарстан Республикасының күрше үзидарәлек берәмлекләренең үзара ярдәм күрсәтү өчен җирле янгын һәм коткару подразделениеләре җәлеп ителергә мөмкин булган торак пунктларының һәм объектларының исемнәрен;
-автоматлаштыру чараларын файдаланганда куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен;

-үзидарәлек районына хас булган ГХ ләрнең (вакыйгаларның) барлыкка килү хәтәрләрен;

-мәгълүмат алмашу тәртибен;

-алдан әзерләнгән исемлек буенча хәбәр итү үткәргәндә АСО-4 белән эшләү тәртибен;

-хәбәр итү сигналларын кабул итү, расланган инструкцияләр нигезендә сигналларны вазыйфаи затларга ирештерү тәртибен.

3.2.2. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең җитәкчесе федераль законнарны, карар, күрсәтмәләрне, югарыгы органнарның боерыкларын һәм башка җитәкче, БКДХ нең эшләвен, ГЛОНАСС – 112 программ тәэмин ителешен билгеләүче норматив-техник һәм методик документларны белергә тиеш.

3.2.3. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ җитәкчесе булдыра алырга тиеш:

- БКДХ алдына куелган бурычларны үтәүне оештыруны һәм контрольне тәэмин итүне;

- БКДХнең эшләвен тәэмин итүне һәм үстерүнең норматив-методик базасын эшләүне, шулай ук чираттагы оператив кизү тору сменасының кизү торуга керешүе турында боерыкларны;

-оператив-техник хезмәтне, БКДХнең шәхси составын һөнәри әзерләүне һәм өйрәтүне оештыруны;

-занятиеләр, тренировкалар һәм өйрәнүләр үткәрүне оештыруны;

- БКДХнең алга таба камилләштерү, үстерү һәм техник коралланышын күтәрү буенча тәкъдимнәр эшләүне.

3.2.4. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ җитәкчесенә таләпләр: югары белем, халыкның һәм территорияләрнең комплекслы куркынычсызлыгы системасында оператив вазыйфаларда кимендә 3 ел оператив эш стажы, билгеләнгән программа буенча уку-өйрәнү, дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшкә керүгә рөхсәт (зарурлык булганда).

3.2.5. БКДХнең оператив кизүе белергә тиеш:

-оператив кизүнең функциональ вазыйфаларын һәм эш тәртибен;

-оператив кизү эшен тәртипкә салучы җитәкче документларны;

-БКДХ эшләвенең структурасы һәм технологиясен;

- БКДХ эшчәнлеген тәртипкә салучы норматив документларны;

- БКДХ оператив кизү торучысының эшчәнлеген ГО сигналлары һәм бүтән сигналлар буенча билгеләүче документларны;

-документларны алып бару кагыйдәләрен.

3.2.6. БКДХнең оператив кизү торучысы булдыра алырга тиеш:

- килүче мәгълүматның дөреслегенә анализ һәм бәяләү үткәрүне;

-мәгълүматны үзвакытында Балык Бистәсе муниципаль районы янгын сүндерү-коткару подразделениеләренә – янгыннар турындагы хәбәрләргә илтифат иткәндә, шулай ук авария-коткару берләшмәләренә һәм РГХС көчләренә – ГХ гә (вакыйгага) илтифат иткәндә җиткерүне тәэмин итүне;

-чакыруларга илтифат иткәндә кичектергесез оператив хезмәтләрнең кизү тору-диспетчерлык хезмәтләре эшчәнлеген яраштыруны;

-ГХ гә (вакыйгага) оператив рәвештә илтифат итү максатларында РГХС ның идарә итү органнары белән җирле үзидарә органнарының хезмәттәшлеген оештыруны;
-элемтә җиһазлары, MicrosoftWindows (Word, Excel, PowerPoint) (яки эквивалент) операцион системасы өчен төп офис кушымталары белән нәтиҗәле эшләүне;
-мәгълүматны кабул иткәндә гарнитурдан файдалануны;
-компьютер артында эшләү белән бер үк вакытта телефоннан ачык, аңлаешлы сөйләшүне;
-фикерләрне белдерү (коммуникатив) күнекмәләрен куллануны;
-карарларны тиз кабул итүне;
-БКДХ алдына куелган бурычларны үтәүне тәэмин итү өчен мәгълүмат чыганакларын нәтиҗәле файдалануны;
-теоретик һәм практик хәзерлек дәрәҗәсен күтәрүне;
-үз вазыйфаларын башкару процессында алынган мәгълүматның яшеренлеген саклауны.

3.2.7 БКДХ нең оператив кизү торучысына тыела:

- телефоннан оператив кизү тору белән бәйле булмаган сөйләшүләр алып бару;

- БКДХ җитәкчесе рөхсәтеннән башка гаммәви мәгълүмат чараларына һәм чит-ят кешеләргә нинди дә булса мәгълүмат бирү;

- БКДХ биналарына чит кешеләрне кертү;

- БКДХ җитәкчесе рөхсәтеннән башка оператив кизү тору урыныннан китеп тору;

-вазыйфаи бурычлар һәм инструкцияләрдә каралмаган вазыйфаларны үтәү;

3.2.8. БКДХ нең оператив кизү торучысына таләпләр:

-эш стажына таләпләр куелмыйча урта һөнәри белем;

- Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ нең эшләвен билгеләүче норматив документларны белү;

-ышанычлы файдаланучы дәрәҗәсендә компьютерда эшләү күнекмәләре (MicrosoftWindows (Word, Excel, PowerPoint не белү яки эквивалент), электрон почта, Интернеттан файдалана алу;

-мәгълүмати белешмәлек системасы белән файдалана белү.

## 3.3. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ биналарына (бүлмәләренә) таләпләр

Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ биналары мәйданнарына ихтыяҗны исәпләү гамәлдәге санитария кагыйдәләре һәм нормалары (СанПиН) таләпләре базасында һәм микъдар составы җирле шартларга, потенциаль куркыныч объектларның булуына һәм ГХләрнең (вакыйгаларның) барлыкка килү хәтәрлегенә бәйле рәвештә, шулай ук үзидарәлек берәмлегендәге халык саныннан, шалтыратуны эшкәртүнең уртача дәвамлылыгыннан һәм тәүлектәге шалтыраулар саныннан чыгып

билгеләнә торган оператив кизү тору сменасы белгечләре санының мөһимлеге нигезендә ясала.

3.4. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ җиһазына таләпләр

3.4.1. БКДХ җиһазына таләпләр, БКДХ нең бурычларын тәүлек әйләнәсе режимында үтәү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 1240-р номерлы күрсәтмәсе белән хупланган үзидарәлек берәмлекләренең бердәм кизү тору-диспетчерлык хезмәтләре базасында бердәм “112” номеры аша кичектергесез оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын төзү Концепциясе нигезендә эшләнде.

3.4.2.Җиһаз составына керергә тиеш, кимендә:

-оператив кизү тору сменасы белгечләренә автоматлаштырылган эш урыны;

-җитәкчелекнең һәм хезмәт күрсәтүче персоналның автоматлаштырылган эш урыны;

-локаль исәпләү челтәренең актив җиһазы;

-структуралы кабель челтәре;

-серверлы җиһаз;

-мәгълүматларны саклауның махсуслашкан чаралары;

-оргтехника комплекты;

-элемтә чаралары;

-хәбәр итүнең җирле системасы белән идарә итүнең автоматлаштырылган эш урыны;

-коллектив кулланылыштагы видео чагылдыру һәм видеоконференцэлемтә системасы чаралары;

-эшләү режимнары үзгәрешенә пакетларны саклау өчен махсус җиһазланган металл сейф;

- метеостанция;

- нурланыш контроле приборы;

- гарантияле электр тукланууы чыганаклары.

3.4.3.Җиһаз составына серверлы җиһаз һәм югары тизлекле исәпләү челтәре белән аерыл алып берләштерелгән мәгълүматларны саклау системасы составында мәгълүматларны эшкәртү үзәге керергә мөмкин. Серверларны сайлау әлеге серверларда эшләү өчен планлаштырыла торган кушымталар яки сервислар өчен җиһазның таләп ителгән җитештерүчәнлеген анализлау нәтиҗәләре нигезендә ясала. Серверлы платформаның тәэмин итү моментыннан кимендә 5 елга җитештерүче тарафыннан расланган, шулай ук БКДХ нең башка элементлары белән ул бергә була ала торган яшәү һәм үсеш планы булырга тиеш. Сервер төшен хәл итү өлешендә иң кулай дип отказоустойчивый сервер кластеры һәм гарантияле электр тукланууны оештыру белән запаска куелган югары

тизлекле исәпләү челтәрендә берләшкән мәгълүматларны запас саклап тору урыны базасында хәл итүне куллану фараз ителә.

### IV. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ эшчәнлеге

4.1. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ үз эшчәнлеген үзидарәлек казна учреждениесе рәвешендә тиңдәшле юридик зат буларак гамәлгә ашыра.

4.2. Балык Бистәсе муниципаль районы БКДХ н төзүне һәм эшчәнлеген финанслау үзидарәлек районы бюджет средстволарыннан, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә бүтән чыганаклардан да гамәлгә ашырыла.

### Төшенчәләр һәм терминнар:

Кизү-диспетчерлык хезмәте (КДХ): Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә эш итүче РГХСның (Россия гадәттән тыш хәлләр системасының) үзидарәлек дәрәҗәсендә ярдәмче системасына керүче һәм даими әзерлектәге көчләре һәм чаралары булган хезмәтнең кизү яки диспетчерлык органы.

БКДХ нең (Бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтенең) идарә итү пункты, БКДХ нең ИП: кизү-диспетчерлык персоналы эше өчен аталган һәм идарә итүнең кирәкле техник, элемтә һәм хәбәр итү чаралары белән җиһазландырылган йорт (корылма, бина).

БКДХ нең элемтә үзәге, БКДХ нең ЭҮ: БКДХ нең идарә пунктында җәелгән элемтә чаралары һәм көчләренең БКДХ һәм гадәттән тыш хәллләрдән халыкны һәм территорияләрне саклау һәм/яки җирле үзидарә каршындагы гражданнар оборонасы өлкәсендә бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле орган мәнфәгатьләрендә мәгълүмат алмашуны тәэмин итүче оештыру-техник берләшмәсе.

БКДХ нең хәбәр итү үзәге, БКДХ нең ХҮ: Хәбәр итүнең һәм персональ чакыруның үзәкләштерелгән хәбәр итүнең җирле автоматлаштырылган системасы белән хезмәттәшлек итүче көч һәм техник чараларының оештыру-техник берләшмәсе.

Автоматлаштырылган система, АС: Персоналдан һәм аның эшчәнлеген автоматлаштыру чаралары комплексыннан торучы, билгеләнгән функцияләрне үтәүнең мәгълүмати технологиясен тормышка ашыручы система.

“Хәвефсез шәһәр” аппарат-программа комплексы, “Хәвефсез шәһәр”АПК: Гамәлдәге һәм перспективадагы федераль, региональ, муниципаль һәм җирле дәрәҗәдәге объектка караган үзара бәйләнгән автоматлаштырылган системалар җыелмасы. Биредә бу системаларның берсенең эшләве икенчесенең эшләү нәтиҗәсенә бәйле. Шунлыктан әлеге җыелманы бердәм автоматлаштырылган система буларак карарга кирәк, ә ул РГХС автоматлаштырылган мәгълүмати-идарә системасының җирле ярдәмче системасының состав өлеше булып тора.

“Оператив илтифат итүнең бердәм үзәге” автоматлаштыру чаралары комплексы, ОИБҮ АЧК: “Хәвефсез шәһәр” АПК н төзегәндә (керткәндә)

БКДХнең җирле региональ кизү-диспетчерлык хезмәтләре һәм 112 системасы белән хезмәттәшлектә эшләү процессларын комплекслы мәгълүматлаштыруны тәэмин итүче программалы-аппарат чараларының оештыру-техник берләшмәсе.

РГХС ның автоматлаштырылган мәгълүмати-идарә итү системасы, РГХС ның АМИС: РГХС ның идарә органнарының эшен тәэмин итү өчен зарур булган мәгълүматларны җыю, саклау, тапшыру, эшкәртү һәм бирү процессларын автоматлаштыру өчен, шулай ук идарә итү карарларын кабул итүгә булышлык итүче процессларны автоматлаштыру, кабул ителгән карарларны кул астындагыларга һәм хезмәттәшлек итүче идарә органнарына җиткерү һәм аларның үтәлешенә контрольлек итү өчен аталган система.

Вакыйга. Гадәттән тыш хәл булып тормаучы булган хәл, аңа илтифат итү Балык Бистәсе муниципаль районы хезмәтләренең көчләрен һәм чараларын җәлеп итү таләп ителә.

Чакыру (вакыйга турында хәбәр): БКДХнә ГХ (вакыйга) турында төрле элемтә каналлары аша кергән мәгълүмат.